**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Иске Суыксу авыл җирлегенең Иске Суыксу авылында гражданнар җыены карары**

13 ноябрь 2025 ел № 1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Иске Суыксу авыл җирлегенең Иске Суыксу авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2026 елда Иске Суыксу авыл җирлегенең Иске Суыксу авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Иске Суыксу авылында торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзүне, ремонтлауны, карап тотуны (юлларга вак таш салуны)?;

- Иске Суыксу авылында торак пункт территориясен төзекләндерү (кышкы чорда юлларны кардан чистарту, җәйге вакытта территорияне чабу, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр алу, эш һәм договор буенча хезмәт күрсәтү өчен түләү)?;

- Иске Суыксу авылындагы зират территориясен төзекләндерү;

3. Җыен нәтиҗәләрен Иске Суыксу авыл җирлегенең Иске Суыксу авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске Суыксу авыл җирлеге башлыгы _________ М.М. Дәүләтшин

Гражданнар җыены секретаре _________ Э.Ф. Билалова